**Татарстан Республикасынын Кукмара муниципаль районы**

**Починок Кучук авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

«28» январь 2022 ел № 1

Починок-Кучук авыл җирлеге Советының 2021 елның 31 январь 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Починок-Кучук авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Починок Кучук авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 январь 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Починок-Кучук авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 декабрендәге 32 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 13 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 2 номерлы, 2019 елның 26 августындагы 10 номерлы, 2021 елның 9 июньдагы 12 номерлы, 2021 елның 23 ноябрьдагы 33 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы Р.Ә. Гыйниятов